**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Тюгеевского сельского**
**поселения Заинского**
**муниципального района**

ул. Центральная, д. 8, с. Тюгеевка,
Заинский район, 423507

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Төги авыл җирлегенең**
**башкарма комитеты**

Үзәк урамы, 8 нче йорт, Төги
авылы, Зәй районы, 423507

Телефон, факс 60-5-02. Электронный адрес: Turg.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.03.2023**

**КАРАР**
**№ 54**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Төги авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны туплау урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү турында**

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 07-ФЗ номерлы, "Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Яктырту җайланмалары, электр лампаларына кагылган өлештә, аларны тиешенчә җыймаганда, тупламаганда, зарарсызландырмаганда, күчереп йөртмәгәндә һәм урнаштырмаганда гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны туплау урынын (урыннарын) түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Зәй районы, Төги авылы, Үзәк урам, 8 йорт.

2. Күп фатирлы йортларда милекчеләр, яллаучылар, биналардан файдаланучылар булып торган терекөмешле лампалар кулланучылар өчен эшкәртелгән терекөмешле лампаларны туплау урыны 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Яктырту җайланмалары, электр лампаларына кагылган өлештә, аларны тиешенчә җыймаганда, тупламаганда, зарарсызландырмаганда, күчереп йөртмәгәндә һәм урнаштырмаганда гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 4 нче пункты белән билгеләнә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терекөмешле лампаларны туплау урыннары, күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле, эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплау урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракта, күпфатирлы йортларда милекчеләр, яллаучылар, биналардан файдаланучылар булып торган терекөмешле лампалар кулланучылар өчен дә дип билгеләргә.

4. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны туплау урынының (урыннарның) урнашуы турында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге җирле үзидарә органы бинасындагы мәгълүмат стендларында (стойкаларында) мәгълүмат урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Т.В. Попова**